Каралды
Башлангыч сыйныф укытучыларының мәктәп методик берләшмә җитәкчесе
__________Э.М. Тухбатуллина
Беркетмә №_1__
«26» август 2017 ел.

Килешенгән
Укыту эшләре буенча директор урынбасары
__________Г.Т.Исмәгыйлова
«28» август 2017 ел

Раслыйм
Мәктәп директоры
__________Г.Т.Сабирҗанова
71нче боерык
«28» август 2017ел

ТР Сарман муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

«Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе»

**Гатина Гөлназ Рафис кызы,**

югары квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы

# ӘДӘБИ УКУ, 1нче в сыйныфы

Каралды
Мәктәп педагогик советы утырышы беркетмәсе №1
«28» август 2017 ел

**2017 – 2018 нче уку елы**

**«Әдәби уку» фәне эш программасына аннотация**

1нче сыйныф өчен эш программасы база дәрәҗәсендә белем бирү программасына нигезләнеп төзелде. Ул Россия Федерациясенең мәгариф турында Федераль Законы, № 273 – ФЗ, декабрь, 2012; Татарстан Республикасының "Мәгариф турында" гы Законы 22.07.2013 №68; Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турында" гы Законы, № 443 РТ, 18.07. 2004; Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандартына.- ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре– Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2010.; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә; "Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә ана теле укыту: гомуми программа"сына -1 – 4 нче сыйныфлар, Ч. М. Харисова, И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина, Казан , 2011.

Программа елга 68 сәгатькә (атнага 2 сәгать) каралган.

Курсның **максаты** — укучыларны татар теленең график системасы төзелеше һәм функциясенең гомуми закончалыклары белән танышу нигезендә башлангыч уку һәм язуга өйрәтү. Бу үз чиратында укучыларда тел турында белем һәм күнекмәләрнең формалашуына нигез булып тора. Грамотага өйрәнү чорында график эшчәнлекне үзләштерү — I сыйныф укучысының **төп бурычы**. Чөнки бу эшчәнлек нәтиҗәсендә балаларда уку һәм язу күнекмәләре формалаша.

Грамотага өйрәнү процессында балаларда татар теле системасының төп тел берәмлекләре (аваз, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст) турында күзаллау туа, фонематик ишетү һәм авазны әйтү культурасы үсә. Алар, **беренчедән**, төрле шартлы модельләр (квадрат, түгәрәк) һәм махсус транскрипция билгеләре системасы нигезендә сүзнең аваз формасын күз алдына китереп әйтә алу; **икенчедән,** сөйләмнең фонетик язуын тиешле басма яки язма хәрефләргә күчерү; **өченчедән**, сүзнең хәреф моделе буенча аваз формасын төзү эшчәнлеген, ягъни уку күнекмәләрен үзләштерәләр. Шул ук вакытта укучылар язма хәрефләрне, аларны иҗекләргә, сүзләргә тоташтырып язу технологиясен дә үзләштерәләр.

«Әлифба» һәм шулай ук «Язу дәфтәре»ндә аваз һәм хәрефләрне өйрәнү эзлеклелеге татар графикасының позицион (иҗек) принцибына нигезләнгән.

Сузык авазлар һәм аларга билге булып килгән хәрефләр беренче чиратта өйрәнелә, чөнки алар иҗек төзи, шуның нигезендә укучылар уку технологиясе белән таныша.

Сузыклардан соң сонор тартыклар өйрәнелә. Бу аларның яңгырау һәм саңгырау парларының булмавы, яңгырашы ягыннан сузык авазларга якын торуына бәйле. Нәкъ менә шушы тартык аваз төркемнәре аша графиканың позицион принцибы төшенчәсе кертелә, ә бу үз чиратында хәрефнең үзенчәлеген янындагы хәрефләр йогынтысында гына белергә мөмкинлекне аңлата. Моны алда өйрәнелгән сузык аваз хәрефләре ярдәмендә күрсәтергә мөмкин: а, ы, у, о хәрефләре — тартык авазның калынлыгын; ә, э, и, ү, ө, е хәрефләре нечкәлеген белдерә. Калын сузык аваз хәрефләре янында тартыкларның — калын, нечкә сузык аваз хәрефләре янында нечкә әйтелүен төшендерү аеруча мөһим.

**Әдәби уку буенча**

## укыту-тематик планлаштыру

**Сыйныф** - 1.

**Сәгатьләр саны**: барлыгы – 66 сәгать; атнага – 2 сәгать.

Эш программасы Россия Федерациясенең мәгариф турында Федераль Законы, № 273 – ФЗ, декабрь, 2012; Татарстан Республикасының “Мәгариф турында” гы Законы 22.07.2013 №68; Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турында” гы Законы, № 443 РТ, 18.07. 2004; Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандартына.- ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре– Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә; “Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә ана теле укыту: гомуми программа” сына -1 – 4 нче сыйныфлар, Ч. М. Харисова, И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина, Казан , 2011; «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең 2017-2018 нчы уку елына укыту планына нигезләнеп эшләнде.

**Дәреслек** -Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова, Р.Р.Шәмсетдинова. Әлифба.1 нче сыйныф: Дәреслек.- Казан: «Мәгариф-вакыт”нәшрияты, 2011 ел;
- Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова, Ф.Ф.Хәсәнова. Әдәби уку. 1 нче сыйныф: Дәреслек.- Казан: «Мәгариф-вакыт”нәшрияты, 2011.
- Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова, Р.Р.Шәмсетдинова. Укытучылар өчен методик кулланма. Әлифба. 1 нче сыйныф.- Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.

## Аңлатма язуы

1нче сыйныфы өчен эш программасы база дәрәҗәсендә белем бирү программасына нигезләнеп төзелде. Ул Россия Федерациясенең мәгариф турында Федераль Законы, № 273 – ФЗ, декабрь, 2012; Татарстан Республикасының “Мәгариф турында” гы

Законы 22.07.2013 №68; Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турында” гы Законы, № 443 РТ, 18.07. 2004; Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандартына.- ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре– Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә; “Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә ана теле укыту: гомуми программа”сына -1 – 4 нче сыйныфлар, Ч. М. Харисова, И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина, Казан , 2011; «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең 2017-2018 нчы уку елына укыту планына нигезләнеп эшләнде.

Программа елга 68 сәгатькә (атнага 2 сәгать) каралган.

Программа үтәлү өчен түбәндәге **укыту-методик әсбаплар** кулланыла:

- Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова, Р.Р.Шәмсетдинова. Әлифба.1 нче сыйныф: Дәреслек.- Казан: «Мәгариф-вакыт”нәшрияты, 2011 ел;- Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова, Ф.Ф.Хәсәнова. Әдәби уку. 1 нче сыйныф: Дәреслек.- Казан: «Мәгариф-вакыт”нәшрияты, 2011.
- Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова, Р.Р.Шәмсетдинова. Укытучылар өчен методик кулланма. Әлифба. 1 нче сыйныф.- Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.
-Г.М.Сафиуллина. Укытучылар өчен методик кулланма. Әдәби уку. 1 нче сыйныф.- Казан: Мәгариф-Вакыт, 2011.

Беренче сыйныфта татар телен өйрәнү “**Грамотага өйрәнү” курсы** белән башлана. Грамотага өйрәнү **өч этаптан** тора: **әзерлек, төп (аваз-хәреф) һәм йомгаклау этаплары**. Баланың мәктәпкә кергәндә үк әзерлеген исәпкә алып, Грамотага өйрәтү чорындагы темалар гомумиләштерелде, эчтәлек сакланды.

Грамотага өйрәнү процессында балаларда татар теле системасының төп тел берәмлекләре (аваз, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст) турында күзаллау туа, фонематик ишетү һәм авазны әйтү культурасы үсә. Алар, **беренчедән**, төрле шартлы модельләр (квадрат, түгәрәк) һәм махсус транскрипция билгеләре системасы нигезендә сүзнең аваз формасын күз алдына китереп әйтә алу; **икенчедән,** сөйләмнең фонетик язуын тиешле басма яки язма хәрефләргә күчерү; **өченчедән**, сүзнең хәреф моделе буенча аваз формасын төзү эшчәнлеген, ягъни уку күнекмәләрен үзләштерәләр. Шул ук вакытта укучылар язма хәрефләрне, аларны иҗекләргә, сүзләргә тоташтырып язу технологиясен дә үзләштерәләр.

Курсның **максаты** — укучыларны татар теленең график системасы төзелеше һәм функциясенең гомуми закончалыклары белән танышу нигезендә башлангыч уку һәм язуга өйрәтү. Бу үз чиратында укучыларда тел турында белем һәм күнекмәләрнең формалашуына нигез булып тора. Грамотага өйрәнү чорында график эшчәнлекне үзләштерү — I сыйныф укучысының **төп бурычы**. Чөнки бу эшчәнлек нәтиҗәсендә балаларда уку һәм язу күнекмәләре формалаша.

Грамотага өйрәнү процессында балаларда татар теле системасының төп тел берәмлекләре (аваз, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст) турында күзаллау туа, фонематик ишетү һәм авазны әйтү культурасы үсә. Алар, **беренчедән**, төрле шартлы модельләр (квадрат, түгәрәк) һәм махсус транскрипция билгеләре системасы нигезендә сүзнең аваз формасын күз алдына китереп әйтә алу; **икенчедән,** сөйләмнең фонетик язуын тиешле басма яки язма хәрефләргә күчерү; **өченчедән**, сүзнең хәреф моделе буенча аваз формасын төзү эшчәнлеген,

ягъни уку күнекмәләрен үзләштерәләр. Шул ук вакытта укучылар язма хәрефләрне, аларны иҗекләргә, сүзләргә тоташтырып язу технологиясен дә үзләштерәләр.

«Әлифба» һәм шулай ук «Язу дәфтәре»ндә аваз һәм хәрефләрне өйрәнү эзлеклелеге татар графикасының позицион (иҗек) принцибына нигезләнгән.

Сузык авазлар һәм аларга билге булып килгән хәрефләр беренче чиратта өйрәнелә, чөнки алар иҗек төзи, шуның нигезендә укучылар уку технологиясе белән таныша.

Сузыклардан соң сонор тартыклар өйрәнелә. Бу аларның яңгырау һәм саңгырау парларының булмавы, яңгырашы ягыннан сузык авазларга якын торуына бәйле. Нәкъ менә шушы тартык аваз төркемнәре аша графиканың позицион принцибы төшенчәсе кертелә, ә бу үз чиратында хәрефнең үзенчәлеген янындагы хәрефләр йогынтысында гына белергә мөмкинлекне аңлата. Моны алда өйрәнелгән сузык аваз хәрефләре ярдәмендә күрсәтергә мөмкин: а, ы, у, о хәрефләре — тартык авазның калынлыгын; ә, э, и, ү, ө, е хәрефләре нечкәлеген белдерә. Калын сузык аваз хәрефләре янында тартыкларның — калын, нечкә сузык аваз хәрефләре янында нечкә әйтелүен төшендерү аеруча мөһим.

Моннан тыш, кыска [й] авазын өйрәнү е, ю, я хәрефләре ике аваз кушылмасына, ягъни [й] һәм тиешле сузыкка билге булып килүе белән дә танышырга ярдәм итә.

Алга таба тартыкларның яңгырау һәм саңгырау парларын өйрәнгәндә, мисалларга таянып, балалар язуда тартыкларның калынлык һәм нечкәлекләрен белдерү кагыйдәләрен ныгыталар.

Соңыннан алар аеру билгеләре [ь,ъ] булган сүзләргә аваз анализы ясарга һәм ул сүзләрне укырга өйрәнәләр, шуннан соң гына парсыз шаулы тартыклар белән танышалар, аларның язылыш үзенчәлекләрен үзләштерәләр.

I сыйныф укучысы кыска гына вакыт эчендә өйрәнелә торган аваз еш кулланылган сүзләрне, текстларны укырга өйрәнә, нәтиҗәдә хәрефләрне тиешле авазларга күчерә.

«Әлифба»да уку өчен махсус төзелгән текстлардан тыш, балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән һәм балаларда танып белү эшчәнлеген формалаштырырга ярдәм итә торган башка жанрдагы әсәрләр: шигырь, табышмак, мәкаль, әйтем, тизәйткеч, санамышлар да урын алган. Грамотага өйрәтү дәресләрендә балаларның фонематик ишетеп аңлау һәм аваз культурасы үсешенә сүзләрне «үстерү» һәм сүзләрне үзгәртеп төзү алымнарын куллану нәтиҗәсендә ирешелә. Сүзләрне «үстерү»нең асылы сүзнең авазлар санын акрынлап үстерә баруда, бу башлангыч сүзнең үзгәрүенә һәм яңа сүзләр ясауга китерә. Мәсәлән: бал — бала — балан — баланлы — баланлык**.** Бу дәреслектәге лексик материалны баетып кына калмый, ә укучыларда күзәтүчәнлекне үстерүгә һәм аңлап уку техникасын формалаштыруга җирлек тудыра. Мондый чылбырдагы сүзләрне уку берьюлы ике дәрәҗәдә башкарыла: а) иҗекләп (җырлап, йөзмә, салмак) уку; ә) авазларны дөрес әйтеп (орфоэпик), басымнарны дөрес куеп уку.

Шулай ук сүзләрне үзгәртеп төзү алымы да кулланыла, бу укучыларга сүзгә бер аваз өстәү яки аның бер авазын үзгәртү нәтиҗәсендә сүзнең мәгънәсе тулысынча үзгәрүне күзәтергә мөмкинлек бирә, мәсәлән: көн — төн, бала — балан һ.б.

Бу этапта жиде яшьлек балалар алдында торган **төп бурыч** булып, басма һәм язма хәреф билгеләренең формаларын үзләштерү тора. Басма һәм язма хәрефләр системасына структур-системалы якын килү нәтиҗәсендә, хәрефләрне төзү максатыннан, аларның элемент-өлгеләре эшләнде. Аларны кулланып, укучы үз куллары белән өйрәнелә торган хәреф формасын мөстәкыйль төзи алуга ирешә.

**“Грамотага өйрәнү” курсыннан соң татар теле һәм әдәби уку фәннәре аерым өйрәнелә башлый.**

**<u>Әдәби уку фәненең бурычлары түбәндәгеләр:</u>**

«Әдәби уку» укыту-методик комплекты түбәндәге мәсьәләләрне хәл итә.

1. «Перспектив башлангыч мәктәп» комплекты чишәргә тиешле гомумдидактик бурычлар: укучы үзенә кирәкле информацияне «Эчтәлек»;битенә карап таба белергә; исеме буенча текстның эчтәлеген күзалларга; күзәтү эшчәнлеген формалаштырырга *(әдәби һәм сәнгать исәрләреннән аерым детальләрне таба, барлык ваклыклары белән сөйләп бирә)* һәм гомумиләштерергә *(аерым детальләргә нигезләнеп, таралган төрле мәгълүматларны берләштереп, бербөтен картина тудырырга);* «акыллы өлкәннәр» белән хат аша аралашу ихтыяҗы формалаштырырга тиеш.
2. Бала яшенә туры килә торган теоретик бурычлар:
а) хайваннар турындагы әкият үзенчәлекләре белән таныштыру: татар халык әкиятләренең, берьяктан, башка халыкларның хайваннар турындагы әкиятләренә охшаш булуы *(төп геройлары — хайваннар, еш кына бер ук төрле мөнәсәбәтләргә керәләр),* икенче яктан, бер-берсеннән аерылуы *(төп геройлар — башка төрле хайваннар, бер-берсе белән мөнәсәбәтләре бөтенләй башка төрле);* хайваннартурышдагы автор әкиятләренең ешкына халык әкияләренә нигезләнүе *(башлангыч сыйныфларда әле автор нигезләнүе термин буларак әйтелми);* халык әкиятләрендә аерымхайваннарның патшалык итүе *(баш булуы);* хайваннар турындагы әкият героеның һәрвакытта көчсезләрне яклаучы гына түгел, еш кына хәйләкәр, тиктормас, көлкегәкалучы икәнлеге турында төшенчә бирү;
ә) әхлакый бурычлар: күзәтүчәнлек, хыяллана белүчәнлек, дуслар белән аралашу, ярата һәм яратыла белү –байлык һәм рухи кыйммәт икәнлеге турында күзаллау булдыру;
б) эстетик бурычлар: матурлык - ул сине чолгап алган тирәлек, бары тик аны күрә белергә кирәкле турында төшенчә бирү;
в) сөйләм телен үстерү бурычлары.
3. Текстта ориентлаша белергә өйрәтү: әсәрләрне өлешләргә бүлү, кирәк урынны табын укып күрсәтү, хис белән белдерелгән өзекнең эчтәлеген ачыклау; әдәби әсәрләргә бәя бирелгәндә һәм сәнгать әсәрләрен караганда предметка - бу «синең» әсәрне аңлау;идеяң икәнен җайлап төшендерү.

**<u>Әдәби укудан гомуми башлангыч белем бирү максат һәм бурычлары:</u>**
-татар әдәбияты хакында беренчел күзаллау булдыру;
-әдәби әсәрләрне дөрес, сәнгатьле, тиз укырга һәм аңларга өйрәтү;
-әдәби текст белән эшләү, текст эчтәлеген үз сүзләре белен сөйләү күнекмәсен камилләштерү;
-мөстәкыйль рәвештә әсәрләрне ,укырга һәм үзләштерергә күнектерү, татар әдәбиятына һәм башка халык әдәбиятларына хөрмәт, китапка кызыксыну булдыру;
-белемгә омтылыш тәрбияләү, укучының иҗади , логик фикерләвен, хәтерен, эстетик зәвыгын үстерү, үз-үзен тәрбияләвенә ирешү.

**Искәрмә:** «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең «Укыту предметы, курсы, дисциплинасының эш программасы турында»гы 2016 нчы елның 27 нчы августында педсоветта каралган (беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августында чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә туры килгән очракта, программа сәгатьләрне берләштерү исәбенә үтәлә.

**Уку предметы эчтәлегенең рухи кыйммәтләре**
Һәр теманы өйрәнгәндә, һәр әсәрләрне анализлаганда түбәндәге **рухи кыйммәтләргә** басым ясала:

-патриотик хисләр ( Туган илгә мәхәббәт; туган җиргә, туган халкыңа хезмәт итү);
-кешеләрне хөрмәт итү(тугрылык, намуслылык,шәфкатьлелек);
- гаиләгә ярдәм итү( әти-әнигә хөрмәт, кечкенәләргә ярдәм итү);
- хезмәтне ярату, алга омтылыш булдыру;
- халыкларның культурасын өйрәнү;
- тынычлык өчен көрәшү.

**Укыту предметын үзләштерүнең шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләре**

**Шәхси нәтиҗәләр**.
**Шәхси универсаль уку гамәлләре**:
- "Гаилә”, "туган ил”, "мәрхәмәтлелек”, "башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү;
- Туган республикага, гаиләгә, туганнарга карата хөрмәт, әти-әнине ярату; үз милләтеңне ярату, татар булуың белән горурлану;
- укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү;
- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләрен һәм геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
**Предметара нәтиҗәләр.**
**Регулятив универсаль уку гамәлләре**:
- Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.
- Укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү.
- Укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү.
- Эш сыйфатына бәя бирә белү.
- Эш барышында гади генә эш приборлары белән эш итә белү.( линейка, бетергеч, карандаш, )
**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**
- Дәреслек белән эш итә белү.
- Хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.
- Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку.
- Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.
- Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
- Укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.
- Предметларны, чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү.
- Укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген сөйли белү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**
- Дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү
- Укытучының, классташларның сорауларына җавап бирү;

- Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.
- Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
- Парларда эшли белү.

| Шәхси универсаль уку гамәлләре. | Регулятив универсаль уку гамәлләре. | Танып-белү универсаль уку гамәлләре. | Коммуникатив универсаль уку гамәлләре. |
|---|---|---|---|
| 1.Түбәндәге кыйммәтләрне аңлый һәм бәяли белү: яхшылык, түземлелек, табигать, туган ил, гаилә һ.б. Үз гаиләңә, туганнарыңа, ата-анаңа хөрмәт.<br>2.Укучы ролен үзләштерү. Укуга карата кызыксыну формалаштыру.<br>3. Гомумкешелек нормалары күзлегеннән чыгып, тормыш ситуацияләрен, геройларның үз-үзләрен тотышларын бәяләү. | 1.Укытучы җитәкчелегендә эш урынын әзерләү, оештыру.<br>2.Укытучы җитәкчелегендә дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү максатын билгеләү.<br>3.Укытучы җитәкчелегендә дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү планын билгеләү. | 1.Китап белән эшләү: бирелгән бүлекне өйрәнгәндә формалашучы белем-күнекмәләрне билгеләү.<br>2.Укытучының гади сорауларына җавап бирү, дәреслектән тиешле мәгълүматны табу.<br>3.Геройларны, аларның гамәлләрен чагыштыру, уртак һәм аермалы якларын табу.<br>4.Укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйләү. | 1.Дәрестә һәм тормыш ситуацияләрендә диалогта катнашу.<br>2.Укытучы, сыйныфташларның сорауларына җавап бирү.<br>3.Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшү, хушлашу,рәхмәт белдерү.<br>4.Башкаларның сөйләмен тыңлап аңлау.<br>5. Парлап һәм күмәк эшләү. |

**Предмет нәтиҗәләре:**
-укытучы, укучы укыган текстны ишетеп аңлау;
-бөтен сүзләрне аңлап, дөрес уку;
-текстны тулысынча сөйләү;
-кечкенә күләмле шигырьләрне ятлау;
-рәсем буенча телдән хикәя төзү;
-автор,текст исеме һәм текстның эчтәлеген билгеләү;
-хикәя , шигырьне аера белү.

**Уку материалының эчтәлеге**

***Әзерлек чоры (4 сәг.)***

Әкият текстын тыңлау. Иллюстрацияләрнең (рәсемнәрнең) текст өлешләре белән бәйләнешен (мөнәсәбәтен) ачыклау. Әкият эчтәлеген сөйләү.

Балаларда текст турында, беренчедән, мәгънә ягыннан үзара бәйләнгән һәм хәбәр итү интонациясе белән әйтелә торган, якынча тәмамланган фикерне белдерүче, билгеле бер эзлеклелектә килгән сүз һәм җөмләләр җыелмасы буларак, икенчедән, нәрсә турында да

булса хәбәр итүче һәм ишетеп, күреп зиһенгә алына торган мәгълүмат буларак башлангыч күзаллау булдыру. Иллюстрация темасы буенча җөмләләр төзү. Конкрет җөмләләр белән текстның график моделе арасындагы мөнәсәбәтне ачыклау. Рәсем белән бирелгән хикәяне исемләү (исем кушу). Текст төзү элементлары. Тәкъдим ителгән график моделе буенча хикәя эчтәлеген сөйләү.

Укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән укытучы сорауларына җавап бирү. Текст эчтәлеген сайлап алып сөйләү, шигырь ятлау.

Телнең структур берәмлеге буларак сүз турында башлангыч күзаллау булдыру. Басма хәрефләрнең элемент-өлгеләре белән танышу.

***Әлифба чоры (36 сәгать)***

**Сузык авазлар**. Сузык [а, ә, ы, э, и, у, ү, о, ө] авазларының сүздә төрле позициядә килгән һәм аерым кулланылган очрактагы артикуляцияләрен ныгыту. Сузык авазларны аеру күнегүләре. Иҗек ясау процессында сузыкларның роле. Сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә. График схема буенча сузык авазны әйткәндә, сузыкка басым куеп әйтү. Сүзнең график схемалары буенча сүзне көйләп,иҗекләргә бүлеп салмак һәм орфоэпик дөрес уку. Сүзнең иҗекләргә бүленешен дуга ярдәмендә билгеләү.

Схемада сузык авазны башта түгәрәк, соңыннан транскрипция билгесе белән билгеләү. Ишетелгән һәм әйтелгән сүзләр арасыннан өйрәнелә торган аваз кергән сүзне таный һәм аера белергә өйрәнү. Өйрәнелгән сузык аваз кергән сүзләр сайлау.

Элемент-өлге ярдәме белән басма хәрефләр төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. Хәреф турында авазның тышкы билгесе, ягъни «киеме» буларак образлы күзаллау булдыру.

**Парсыз сонор тартык авазлар**:[м, н, л, р, й, ң] сонор тартык авазлары. Бирелгән авазларның артикуляциясе : үпкәдән килә торган һава агымы бер сөйләм органында, мәсәлән иреннәрдә, тешләрдә, тел алдында, тел уртасында, тел артында киртәгә яки тоткарлыкка очрый, бу авазларны әйткәндә тон өстенлек итә, шау катнаша гына. Шуңа күрә ул авазларны ярым сузыклар дип тә йөртәләр.

Калын һәм нечкә яңгырашлы сүзләрдә сонор тартык авазлар әйтелешен чагыштыру; язуда аларның калын яңгырашын калын сузык аваз хәрефләре (а, у, о, ы) белән (ма, му), нечкә яңгырашын нечкә сузык аваз хәрефләре (ә, и, ө, ү, э) белән белдерү. Сүздә һәр авазны аерып әйтү алымы. Рәсем һәм схема белән бирелгән сүзләргә аваз анализы. Анализлана торган сүз составына кергән аерым аваз артикуляциясе. Тартык авазларның яңгыраулыгын белдерүче билге — уртасында нокта булган квадрат белән билгеләү.

Чагыштыру өчен бирелгән сүзләрдәге (мал-мәл) авазларның аермалы билгеләренең мәгънә функциясенә ия булуын билгеләү.

Сонор авазларны белдерүче басма баш һәм юл хәрефләрнең формаларын үзләштерү. Ябык иҗекләрне (ай) һәм калын һәм нечкә яңгырашлы кушылмаларны (ма, мә, му, мү һ.б.), шулай ук парсыз тартык авазлар уртада һәм ахырда булган сүзләрне (май, малай) уку. Сүзләрне иҗекләп уку белән чагыштырып, орфоэпик уку һәм әйтү алымы.

**Сүз башында һәм сүз уртасында |й] авазы**:Я, е, ю хәрефләренең ике авазга [йа], [йә], [йы], [йә], [йу], [йү] билге булып килүләре: яра, ял, юл, куян, баян.

Аваз-хәреф схемаларын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп уку. Шартлы билгеләр һәм басма хәрефләр нигезендә сүзнең аваз формасын график формага күчерү процессын күзәтү.

Я, е, ю хәрефләрен куллану кагыйдәләрен үзләштерү. Бу хәрефләр кергән сүзләрне һәм иҗекләрне уку. Баш һәм юл басма хәреф формаларын төзү.

**Яңгырау һәм саңгырау парлары булган тартыклар:**Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны калын һәм нечкә яңгырашын билгеләү: нечкәлек яңгырау, саңгырау ([д-т],[з-с],[г-к],[гъ-къ] һ.б.) парларның үзара мөнәсәбәтен ачыклау. Мәсәлән бар-бар, бар-пар һ.б. Өйрәнү тәртибендә басма хәреф формаларын үзләштерү.

Авазларында аерма булган сүзләрне, яңгырау һәм саңгырау тартык авазлардан башланган сүзләрне әйтеп карау, чагыштыру күнегүләре (бар-пар).

Аваз-хәреф схемалары нигезендә авазларны аеру, иҗекләр, сүзләр, текстлар уку.

Башлангыч сүзне һәм сүзнең авазын алмаштыру яки аваз өстәү юлы белән ясалган яңа сүзләрне (бур-бура-буран), шулай ук ике яктан да бертөрле укыла торган (ана) сүзләрне уку. Табышмаклар уку һәм аларның җавабын табу. Тизәйткечләр, санамышлар, үртәвечләр, өйрәнелә торган аваз булган халык мәкальләрен уку, истә калдыру һәм хәтер буенча сөйләү.

Аваз. иҗек.сүз.җөмлә һәм текст турында образлы күзаллау формалаштыру.

А**еру билгеләре булып торган ь һәм ъ тан соң [й] авазы**:Язуда аеру билгеләре булып торган ь һәм ъ һәм сузык аваз хәрефләре ярдәмендә [й] авазының язуда бирелешен (ь+е,я, ю; ъ+е, ю, я) аңлату. (Я, е, ю хәрефләре алдындагы иҗек калын сүзләргә (алъяпкыч) ъ билгесе, алдагы иҗек нечкә сүзләргә (дөнья) ь билгесе куелуын аңлатыла).

Аеру билгеләре һәм сузык аваз хәрефләре белән белдерелгән [й] авазлы сүзләрнең аваз анализы. [Й] авазы кергән сүзләрнең аваз схемасын уку. аны хәреф формасына үзгәртү, соңыннан башта иҗекләп, аннан соң орфоэпик дөрес итеп уку.

ь, ъ билгеләренең басма хәрефләрен төзү һәм аларның формаларын үзләштерү.

(Бу билгеләрнең [гъ], [къ] авазларының калынлыгын белдерү өчен дә кулланылуын аңлату (игътибар, тәкъдим). Калын[гъ] һәм [къ] авазлары булган сүзләрнең калынлыгын белдерү өчен язуда калын сузык аваз хәрефләре куланылуын, әйткәндә, иҗек нечкәлеген белдерү өчен, ахырдан ь билгесе куелуын ассызыклан үтәргә кирәк. Мәсәлән мәкаль сүзендә[къ] калын кече тел тартыгы, аның калынлыгын белдерү өчен к дан соң а язабыз, укыганда [мәкъәл] дип укыйбыз, икенче иҗекне нечкә итеп уку өчен сүз ахырына ь билгесе куябыз.)

**Парсыз тарлык авазлар**:Парсыз [х, һ, щ, ц] тартыклар артикуляциясе. Бу авазларның характеристикасы. Парсыз тартык авазлар кергән иҗекләр һәм сүзләр, текстлар уку. Текстның эчтәлеген үзләштерү. Эчтәлеген сөйләү. Басма хәрефләрнең формаларын үзләштерү.

***Әлифбадан соңгы чор ( 2 сәг.)***

Төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен формалаштыру. Текстагы «авыр» (озын һәм таныш булмаган) сүзләрне укыганда иҗекләп укырга мөмкин. Җөмләнең тыныш билгеләренә карап җөмләләр арасында тукталыш (пауза) ясау. Хикәяләү, сорау, тойгылы җөмләләрнең интонациясен бирү. Укылган текст буенча бирелгән сорауларга тулы җавап бирү. сайлап алып эчтәлеген сөйләү, текстның башын, ахырын үзгәртү, аңа яңа исем бирә белү күнекмәләренә ия булу.

Текстның

1) башлам (вакыйга нәрсәдән башлана).

2) төп өлеш (катнашучы-геройлар белән нәрсә була),

3) йомгаклауга(нәрсә ничек төгәлләнә) туры килә торган кисәкләрен табу һәм уку. Текста сурәтләнгән вакыйгаларга укучы баланың һәм авторның мөнәсәбәтен белдерә белү

**“Әдәби уку” предметының эчтәлеге (24 сәгать)**

Балалар Элифбадан әдәби укуга сиздермичә генә, эзлекле рәвештә күчәргә тиеш. Кече яшьтәге мәктәп балалары аңлап укуның беренчел күнекмәләрен ала, халык авыз иҗатының жанрлары белән таныша һәм аларны тормышта кулланырга өйрәнә. Аптыраткыч-алдавыч, әйләнмәле, чылбыр әкиятләрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен аера, авторларның чәчмә һәм шигъри текстлары белән

таныша. Халык авыз иҗаты һәм шагыйрьләрнең шигъри әсәрләре аша, юл ахырындагы охшаш сүзләргә нигезләнеп, рифма, кабатлаулар, сәнгатьлелек турында беренчел күзаллау булдырыла.

Кыска текстлар һәм аларга ясалган иллюстраөияләрне чагыштырып, әдәби образның сәнгатьнең төрле төрләрендә тасвирлануы аңлатыла.

Беренче сыйныфны тәмамлаганда, бала текстны аңлап укырга һәм аның эчтәлеге буенча үз фикерләрен әйтә белергә тиеш (дәреслектә бирелгән конкрет сорауларга җавап бирү формасында).

Балаларда халык авыз иҗаты турында гомуми күзаллау булдырыла, алар проза һәм поэзиянең үзенчелекләрен танып беләләр, “автор”, “әсәрнең исеме” төшенчәләре бирелә, әсәрдәге персонажларны танып әйтә алалар.

Программа әдәби әсәрләр белән эшләү юллары, алымнары белән таныштыра, шул ук вакытта укытучыга иҗади эшләү мөмкинлеге дә калдыра.

**Шигырь һәм проза**. Шигъри һәм чәчмә әсәрләр турында гомуми күзаллау булдыру. Әдәби әсәрнең исеме, авторы (язучы, шагыйрь), халык авыз иҗатында билгесезлек (авторы юк).

**Халык авыз иҗаты һәм әдәбият**

Халык авыз иҗаты турында гомуми күзаллау булдыру. Авторның булмавы, телдән сөйләм, практик-уен характерындагы кече жанр әсәрләре. Бишек җырлары, санамыш, табышмак, тизәйткеч, эндәшләр. Әйләнмәле һәм чылбыр әкиятләр. Халык авыз иҗатының табышмак, әйләнмәле әкият кебек формаларын практик яктан үзләштерү.

Сурәтләнгән вакыйгаларга карата автор фикере (әсәр исеме, геройларга характеристика, авторлар бәяләмәсе).

**Әсәрнең эмоциональ тоны**

Юмористик һәм җитди характердагы әсәрләр. Әсәрләрне китаптан кычкырып яисә яттан укыганда, эмоциональ, тон, тавыш көче, тембр, темп, пауза, логик басым, сузсез мимика, хәрәкәтләр, ымнарны дөрес бирә алу.

**Әдәби сәнгатьлелек чаралары**

Текстны анализлау барышында сәнгатьлелек чараларын табарга күнектерү. Сурәтләү чаралары турында беренчел күзаллау булдыру, кабатлауларның мәгънәсенә төшенү, тавышның сәнгатьлелеген ачыклау: рифма, ритм төшенчәсе бирү.

**Әдәби жанрлар**

Жанрлар турында гомуми күзаллау булдыру.

**Хикәя.** Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү. Әсәрдәге геройларга карата үз фикерен белдерү.

**Шигырь**. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү, шагыйрьнең матурлыкны тоя белергә өйрәтүе. Рифма белән танышу: аны таба, куллана белергә күнектерү.

**Библиографик культура**. Дәреслектә җиңел генә ориентлашырга өйрәтү: эчтәлек битеннән кирәкле әсәрне тиз генә эзләп табу.

**Уку күнекмәләре**. Укучыларны тиз һәм йөгерек укырга гадәтләндерү. Укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклау, дөрес тавыш төсмерләре (тавыш көче, темпы) белән укырга өйрәтү. Төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен формалаштыру. Текстагы «авыр» (озын һәм таныш булмаган) сүзләрне укыганда иҗекләп укырга мөмкин. Җөмләнең тыныш билгеләренә карап җөмләләр арасында тукталыш (пауза) ясау. Хикәяләү, сорау, тойгылы җөмләләрнең интонациясен бирү. Укылган текст буенча бирелгән сорауларга тулы җавап бирү. сайлап алып эчтәлеген сөйләү, текстның башын, ахырын үзгәртү, аңа яңа исем бирә белү күнекмәләренә ия булу. Текстның **1) башлам** (вакыйга нәрсәдән башлана). **2) төп өлеш** (катнашучы-геройлар белән нәрсә була), **3) йомгаклауга** (нәрсә ничек төгәлләнә) туры килә торган кисәкләрен табу һәм уку.

## Сәгатьләр санының тематик бүленеше

| № | Бүлекләр,темалар | Сәгать саны |
|---|---|---|
| | Әлифба чоры | |
| 1. | Әзерлек чоры. | 4 |
| 2. | Төп чор - Әлифба чоры. | 36 |
| 3 | Әлифбадан соңгы чор | 2 |
| | | 42 |
| | Әдәби уку | |
| 3 | 1 бүлек: “Сәяхәткә чыгу” | 3 |
| 4 | 2 бүлек: “Кайтаваз мәгарәсе” | 3 |
| 5 | 3 бүлек: “Аю өне янында” | 2 |
| 6 | 4 бүлек: “Чәчәкле аланда” | 2 |
| 7 | 5 бүлек: “Урман мәктәбендә” | 2 |
| 8 | 6 бүлек: “Шүрәледә кунакта” | 11 |
| 9 | 7 бүлек: “Китап рәссамы күргәзмәсендә” | 1 |
| | | 24 |
| | Барлыгы | 66 |

| № | Дәрес темасы | Укыту эшчәнлеге төрләре | Дата | |
|---|---|---|---|---|
| 1 чирек – 17 сәг.<br>Әзерлек чоры (4 сәг.) | | | план | факт |
| 1 | Сөйләм. “Өч кыз”, “Куян кызы” әкиятләре. | Җөмләләр, сөйләм төзү. Җөмләне график сурәтләү. | 04.09 | 4 |
| 2 | Сөйләм. Җөмлә. Текст.Ипи ничек өстәлгә килә. | Җөмләләр, сөйләм төзү. җөмләне график сурәтләү. | 06.09 | 6 |
| 3 | Текст. “Яшелчә бакчасы”. “Алма бакчасы”. “ Көз”. | Авазлар. Әйтелгән сүздән аерым сузык яки тартык авазны ишетеп, аерып алу | 11.09 | 11 |
| 4 | Җөмлә. Текст.<br>“Зирәк чәүкә”. “Кыш”. “Җимлек”. | Сүздәге авазларның санын һәм эзлеклелеген билгеләү | 13.09 | 13 |
| 5 | Сузык [а] авазы,<br>А, а хәрефләре. | Сүздән сузык [а] авазын аерырга өйрәнү. Иҗек- аваз анализы ясау. | 18.09 | 18 |
| 6 | Сузык [ә] авазы,<br>Ә, ә хәрефләре | Сүздән сузык<br>[ ә] авазын аерырга өйрәнү. Иҗек- аваз анализы ясау. | 20.09 | 20 |
| 7 | Сузык [ы] авазы,<br>Ы, ы хәрефләре.<br>Сузык [э] авазы,<br>Э э , э-е хәрефләре. | Сүздән сузык<br>[ ы] авазын аерырга өйрәнү. Иҗек- аваз анализы ясау.<br>Сузык [э] авазы, Э, э хәрефләре белән танышу, өйрәнгән хәрефләр белән уку, Иҗек- аваз анализы ясау | 25.09 | 25 |
| 8 | Сузык [и] авазы,<br>И, и хәрефләре. | Сүздән сузык [ и] авазын аерырга өйрәнү. Иҗек- аваз анализы ясау. | 27.09 | 27 |
| 9 | Сузык [у] авазы,<br>У, у хәрефләре.<br>Сузык [ү] авазы,<br>Ү, ү хәрефләре | Сүздән сузык [у] авазын аерырга өйрәнү. Иҗек- аваз анализы ясау, сүзләр уйлап әйтү, җөмлә төзү. Сүздән сузык [ү] авазын аерырга өйрәнү. Иҗек- аваз анализы ясау, сүзләр уйлап әйтү, җөмлә төзү | 2.10 | 2 |
| 10 | Сузык [о] авазы,<br>О, о хәрефләре. | Сузык [о] авазы, О, о хәрефләре белән танышу, О хәрефе сүзнең беренче иҗе-гендә генә килүен аңлау. | 04.10 | |
| 11 | Сузык [ө] авазы,<br>Ө, ө хәрефләре | Сузык [ө] авазы, Ө,ө хәрефләре белән танышу, Ө хәрефе сүзнең беренче иҗегендә генә килүен аңлау. | 09.10 | |
| 12 | Тартык [н] авазы,<br>Н, н хәрефләре. | Яңа аваз, хәреф белән танышу, өйрәнгән хәрефләр белән кушып уку | 11.10 | |
| 13 | Тартык [л] авазы,<br>Л, л хәрефләре | Яңа аваз, хәреф белән танышу, өйрәнгән хәрефләр белән кушып уку. | 16.10 | |
| 14 | Тартык [м] авазы, | Борын аваз хәрефе белән танышу, сөйләм төзү, уку | 18.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | М, м хәрефләре | | | |
| 15 | Тартык [р] авазы,<br>Р, р хәрефләре. | Яңа аваз, хәреф белән танышу, өйрәнгән хәрефләр белән уку, калын, нечкә әйтелешле сүзләр уку. | 23.10 | |
| 16 | Сузыктан соң килгән [й] авазы. | Яңа аваз, хәреф белән танышу, өйрәнгән хәрефләр белән кушылма ясап уку, табышмак уку | 25.10 | |
| 17 | Тартык [ң] авазы,<br>ң хәрефе | Яңа аваз, хәреф белән танышу, өйрәнгән хәрефләр белән кушылма ясап уку, табышмак уку. | 6.11 | |
| 18 | Сузык [йа,йә] авазлары.<br>Я, я хәрефләре. | Ике авазга ия хәреф белән танышу, калын, нечкә әйте-леше белән танышу, өйрән-гән хәрефләр белән уку. | 8.11 | |
| 19 | Сузык [йу,йү] авазлары һәм Ю,ю хәрефләре. | Ике авазга ия хәреф белән танышу, калын, нечкә әйтелеше белән танышу, өйрән-гән хәрефләр белән уку. | 13.11 | |
| 20 | Сузык е хәрефенең [йы] [йэ] авазларын белдерүе. | Ике авазга ия хәреф белән танышу, калын, нечкә әйтелеше белән танышу. | 15.11 | |
| 21 | Тартык [д] авазы,<br>Д, д хәрефләре. | Иҗек- аваз анализы ясау, сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын чагыштыру. | 20.11 | |
| 22 | Тартык [т] авазы,<br>Т, т хәрефләре | Яңа аваз, хәреф белән танышу, өйрәнгән хәрефләр белән кушып уку. | 22.11 | |
| 23 | Тартык [з] авазы,<br>З, з хәрефләре. | Иҗек- аваз анализы ясау, сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын чагыштыру, з һәм с ның әйтелешен чагыштыру | 27.11 | |
| 24 | Тартык [с] авазы,<br>С, с хәрефләре. | Яңа аваз, хәреф белән танышу, өйрәнгән хәрефләр белән кушып уку | 29.11 | |
| 25 | Тартык [г], [г] авазы,<br>Г, г хәрефләре. | Иҗек- аваз анализы ясау, сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын чагыштыру. | 4.12 | |
| 26 | Тартык [к], [к] авазлары,<br>К, к хәрефләре. | Яңа аваз, хәреф белән танышу, өйрәнгән хәрефләр белән уку, калын, нечкә әйтелешле сүзләр уку. | 06.12 | |
| 27 | Ирен – ирен [w] һәм ирен – теш [в] авазлары,<br>В, в хәрефләре | Иҗек- аваз анализы ясау, сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын чагыштыру | 11.12 | |
| 28 | Тартык [ф] авазы,<br>Ф, ф хәрефләре. | Иҗек- аваз анализы ясау, сүзләрнең әйтелешен һәм язы-лышын чагыштыру | 13.12 | |
| 29 | Тартык [б] авазы,<br>Б, б хәрефләре. | Иҗек- аваз анализы ясау, Яңа аваз, хәреф белән танышу, тизәйткечләр уку. | 18.12 | |
| 30 | Тартык [п] авазы,<br>П, п хәрефләре. | Иҗек- аваз анализы ясау, сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын чагыштыру | 20.12 | |
| | | **3нче чирек** | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 31 | Тартык [ж] авазы,<br>Ж, ж хәрефләре. | Иҗек- аваз анализы ясау, сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын чагыштыру | 8.01 | |
| 32 | Тартык [ш] авазы,<br>Ш, ш хәрефләре. | Яңа аваз, хәреф белән танышу, өйрәнгән хәрефләр белән уку, калын, нечкә сүзләр уку, “Ташбака белән” әкияте белән танышу. | 10.01 | |
| 33 | Тартык [җ] авазы,<br>Җ, җ хәрефләре. | Иҗек- аваз анализы ясау, сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын чагыштыру | 15.01 | |
| 34 | Тартык [ч] авазы,<br>Ч, ч хәрефләре. | Иҗек- аваз анализы ясау, Яңа аваз, хәреф белән танышу, | 17.01 | |
| 35 | Тартык [х] авазы,<br>Х, х хәрефләре. | Парсыз тартык [х] авазы, Х, х хәрефе белән танышу, иҗек- аваз анализы ясау. | 22.01 | |
| 36 | Тартык [Һ] авазы,<br>Һ, һ хәрефләре. | Парсыз тартык [h] авазы, Һ,h хәрефе белән танышу, иҗек- аваз анализы ясау, һәйкәлләр белән танышу. | 24.01 | |
| 37 | Сузык ё хәрефенең [йо] авазын белдерүе. | Ике авазга ия хәреф белән танышу, калын, әйтелеше белән танышу. | 29.01 | |
| 38 | Тартык [щ] авазы,<br>Щ, щ хәрефләре. | Тартык [щ] авазы, Щ, щ хәрефләренең рус теленнән кергән сүзләрдә язылуын күрү. | 31.01 | |
| 39 | Тартык [ц] авазы,<br>Ц, ц хәрефләре. | Тартык [ц] авазы, Ц, ц хәрефләренең рус теленнән кергән сүзләрдә язылуын күрү. | 5.02 | |
| 40 | Ъ – калынлык, аеру билгесе. Ь – нечкәлек һәм аеру билгесе. | Калынлык, аеру билгесе, сәнгатьле уку, сорауларга җавап бирү.Ъ нең тавышсыз хәреф икәнен белү. Нечкәлек һәм аеру билгесе белән танышу, сәнгатьле уку, сорауларга җавап бирү. | 07.02 | |
| 41 | Г.Тукай “Туган тел”, Р.Бәшәр “Туган җир”, Р.Вәлиева “Иң матур җир”. | Г. Тукай иҗаты белән таныштыру. Туган тел ни өчен кирәк? Туган җир нәрсә ул? кебек сорауларга җавап бирү. Мультфильм “Туган тел” карау. Ш. Галиев һәм Й.Шәрәпова иҗаты белән танышу. Шигырьләрне сәнгатьле уку. | 12.02 | |
| 42 | Ш.Галиев “Телевизор булды баш”, Й.Шәрәпова “Батыр”, Р.Миңнуллин “Татарлар” | | 14.02 | |

**Әдәби уку (24 сәг.)**

| № | Дәрес темасы | Укыту эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| **1 нче бүлек.Сәяхәткә чыгу**. ( 3 сәг.) | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1/ 43. | Дәреслек белән танышу.<br><br>Аптыраткыч-йөдәткеч әкиятләр.<br>*(Д. 1-7б.,)* | “Әдәби уку” дәреслеге белән танышу. Шартлы билгеләр системасы. Дәреслекнең эчтәлеге. Сүзлекчә. Әсәрнең авторлары. Халык авыз иҗаты әсәрләре белән танышу. Аптыраткыч-йөдәткеч әкиятләр турында кыскача мәгълүмат бирү. | 26.02 | |
| 2/44 | Халык авыз иҗаты.<br>Санамышлар.<br>Табышмаклар<br>*(Д. 8-15б., Х.9 -10 б.,41б.)* | Җавапларын дәлилләргә өйрәтү. Йозак һәм ачкыч, җил һәм капка турында әкият уйлау.<br>Санамышлар белән танышу. Партадашың белән санамышлар әйтеп карау.<br>Эндәшләрне сәнгатьле итеп уку. Тизәйткечләрне әйтү. Хрестоматия белән эшләү.<br>Сорауларга тулы, матур җаваплар әзерләү. Дәреслектәге табышмакларның җавапларын табу.Үз фикерләрен дәлилли белү | 28.02 | |
| 3/45. | Эндәшләр.<br>Тизәйткечләр.<br>*(Д. 16-20б., Х.9.)* | | 5.03 | |
| 4/46. | М.Галиев. Кайтаваз.<br>*(Д. 22-25б.)*<br>*(Х 11-12б)* | Автор һәм халык әкиятләре. Әкиятнең төп уе. Әкияттәге диалогларны сәнгатьле уку. Халык әкиятләренең төзелешен ачыклау, эчтәлек белән танышу. | 07.03 | |
| 5/47. | Рифма.Рафис Корбан.Яңгыр яуганда.<br>(Д 24-27б. , Х 10-11б.) | “Рифма” төшенчәсен куллану..Бәйләнешле сөйләмне үстерү. | 12.03 | |
| 6/48. | Ләбиб Лерон. Буталмышлар илендә.<br>Сабантуй галәмәтләре. | Сабантуй турында әңгәмә. Л. Лерон белән таныштыру. Шигырьләре өстендә эшләү.<br>Рольләргә бүлеп һәм чылбыр буенча сәнгатьле итеп уку. | 14.03 | |
| 7/49. | Х.Халиков “Бии белмәгән аю” “Аю белән өч кыз” әкияте.<br>*(Д. 30-34б.)* | Әдәплелек, әхлаклылык турында әңгәмә үткәрү. Х.Халиков белән таныштыру.<br>“Бии белмәгән аю” шигырен уку.<br>Рәсем буенча эш. Аю турында сөйләшү. Укылган әкиятләрне искә төшерү. Аю белән өч кыз” әкиятен укып, фикер алышу.<br>“Аю белән өч кыз әкияте”н аңлап, сәнгатьле укырга өйрәнү өстендә эшләү.<br>Чылбыр әкиятләрне табу. “Бияләй” әкиятен сөйләү. Үз фикерләрен белдерү, дәлилләү. Рәсемнәр буенча татар халык әкиятләрен тану | 19.03 | |
| 8/50. | Чылбыр әкиятләр.<br>*(Д 34-35 б.<br>Х. 13-17б.)* | | 21.03 | |
| 9/51. | Рәшит Бәшәр. Авылга кайту.<br>Ф.Яруллин Черкиләр җыры.Р.Бәшәр Авазлар.<br>*(Д-36-39б., 20-24 б.)* | Ф. Яруллинның “Черкиләр җыры” шигы-рен сәнгатьле укырга өйрәнү. Хрестоматия белән эш. Ф. Ярул-лин турында кыскача белешмә бирү. Р. Бәшәрнең “Авазлар” шигырен сәнгатьле уку. Сорауларга тулы җавап бирү. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү өстендә эшләү | 4.04 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10/52. | Э.Шәрифуллина.Бәйрәм ашы-кара-каршы.<br>*(Д. 39-42 б.,)* | Табигатьнең шагыйрьләр, рәс-самнар, композиторлар өчен ил-һам чыганагы булуын аңлату. Табигать турында сөйләшү.<br>Кошлар турындагы китаплар күргәзмәсен карау.Рәсем буенча хикәя төзү.<br>Э. Шәрифуллинаның “Бәйрәм ашы-кара-каршы” әкияте өстендәэш. Өлешләргә исем бирү, эчтәлеген сөйләү.<br>Э. Шәрифуллина турында кыскача белешмә бирү. Рольләргә бүлеп уку. Әкиятне дәвам итү. | 09.04 | |
| 11/53 | Урман мәктәбендә. Шигырьләр<br>*(Д.44-46б, Х. 19-24б)* | Бәйләнешле сөйләмне үстерү өчен тематик картиналар белән эш | 11.04 | |
| 12/54. | Ярдәм кулы сузу.<br>Р. Миңнуллин һәм Ш. Галиев шигырьләре.<br>Өтерне кайда куярга?<br>*(Д.46-51б. Х.36-40б.)* | Шигырьләрне уку.<br>Җәнлекләргә, кешеләргә файда китерә торган үләннәр турында сөйләшү. Рәәсемнәр, гербарийлар карау, тану. Үзләре теләгән шигырьләрне яттан өйрәнү. Тыныш билгеләре турында сөй-ләшү. “Өтерне кайда куярга?” шигырен төрлечә укыту, чагыштыру, нәтиҗә ясау | 16.04 | |
| 13/55. | Р.Кутуй. “Төнге әкият” | Рөстәм Кутуй, Р.Хисмәтуллин, Х.Халиков турындда кыскача белешмә бирү.Шигырьләрне укыту. | 18.04 | |
| 14/56 | Р.Хисмәтуллин “Хәерле иртә!”, Х.Халиков.<br>” Әгәр күрә белсәгез” | | 23.04 | |
| 15/57. | Р. Вәлиева. “Кыңгырау чәчәк”<br>*(Д 57-59 б.<br>Х. 31)* | Р. Вәлиева турында кыскача белешмә бирү. “Кыңгырау чәчәк” әкиятен уку. Эчтәлеге өстендә эшләү. Дуслык һәм яхшылык турында әңгәмә үткәрү. | 25.04 | |
| 16/58. | Х.Халиков.<br>“Көймәче мәче”. Р.Харис “Сине көтә тыныч таң”<br>(*Д.61-65б.)* | Халык авыз иҗаты төрләре – такмазалар, үртәвечләр, бишек җырлары белән таныштыру.<br>Р. Харисның “Сине көтә тыныч таң” шигырен сәнгатьле укыту. Соауларга җавап алу. | 30.04 | |
| 17/59. | М.Әгъләмов.”Килсен безгә әкият”.<br>(*Д.66-67б.)* | Халык авыз иҗаты төрләре – такмазалар, үртәвечләр, бишек җырлары белән таныштыру.<br>Р. Харисның “Сине көтә тыныч таң” шигырен сәнгатьле укыту. Соауларга җавап алу. | 2.05 | |
| 18/60. | Р.Вәлиева “Урман әкияте”.<br>(Х..31-3 5б.) | Шигырьләрне сәнгатьле итеп уку. Хикмәтле сүзләрне табу. | 7.05 | |
| 19/61 | Х.Туфан. “Юкмыш бабай малае”.<br>*(Д. 68-71б.)* | Шигырьләрне сәнгатьле итеп уку. Хикмәтле сүзләрне табу. | 09.05 | |
| 20/62. | “Буталмыш әкият”. “Шүрәле”<br>(*Д.71-73б.)* | Атна көннәренең исемнәрен истә калдыру.Авазадаш сүзләрне табу. Шигырьне яттан сөйләү. | 14.05 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 21/63. | .Г. Тукай «Шүрәле”<br>(Х.53-54 б.) | Г.Тукай «Шүрәле” әкиятеннән өзек тыңларга. | 16.05 | |
| 22/64. | Р.Корбан “Шүрәле рәхмәт әйткән”. М.Галиев “Шүрәле һәм җил”<br>*(Х .54-56б.)* | Әсәрләрне сәнгатле итеп укырга | 21.05 | |
| 23/65. | Р.Харис “Матур өй”<br>*( Х 59-64б.)* | Хикәяне мәгънәви кисәкләргә бүлү, әсәрнең төп уен билгеләү. Тест биремнәрен үтәү. | 23.05 | |
| 24/66 | Китап рәссамы күргәзмәсендә.Үткәннәрне кабатлау | Соауларга җавап алу. | 25.05 | |

**Кулланылынган әдәбият:**

**Укучылар өчен әдәбият:**

1. Ф.Гарифуллина, И.Мияссарова, Р.Шәмсетдинова. Әлифба . 1 нче сыйныф: Дәреслек. - Казан: «Мәгариф-вакыт”нәшрияты, 2011.
2.Г.М.Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина, Ә.Г. Мөхәммәтҗанова, Ф.Ф. Хәсәнова . Әдәби уку. 1 нче сыйныф: Дәреслек. - Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2011.

**Укытучы өчен әдәбият:**

1. Ф.Гарифуллина, И.Мияссарова, Р.Шәмсетдинова. Әлифба . 1 нче сыйныф: Дәреслек. - Казан: «Мәгариф-вакыт”нәшрияты, 2011.
2.Г.М.Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина, Ә.Г. Мөхәммәтҗанова, Ф.Ф. Хәсәнова . Әдәби уку. 1 нче сыйныф: Дәреслек. - Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2011.
3. Г.М.Сафиуллина. Укытучылар өчен методик кулланма. Әдәби уку. 1 нче сыйныф.- Казан: Мәгариф-Вакыт, 2011.
4. Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова, Р.Р.Шәмсетдинова. Укытучылар өчен методик кулланма. Әлифба. 1 нче сыйныф.- Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.

**Интернет-ресурслар:**

kitaphane.tatar.ru/sad.htm
http://www.tatmedia.com.
http://www.tatarstan.ru/books/
*http*://www.kitap.net.ru
tarkhanova.ru
gzalilova.narod.ru
tatartele2010.ucoz.ru
tugan-tel.blogspot.com
tatartele5.edu.tatar.ru
belem.ru
forum.tatar.info›index.php

**Эш формалары:**

- фронталь;
- парлы;
- группада;
- индивидуаль.

**Алымнар:**

- практик;
- иллюстратив аңлату;
- өлешчә эзләнү;
- күзәтү.

**Чаралар:**

- техник чаралар;
- модельләр һәм таблицалар;
- рәсемнәр;

- дидактик материаллар.

**Диагностика формалары:**

- дөрес һәм аңлап укуны тикшерү – 1.